ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18 12 2023 г. № 269

**2024 елга Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәрендә торак урынын тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлешенә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясына ярашлы рәвештә, «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннары хуҗалары өчен торак бинаны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик киңәшләрне раслау, торак урынын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү турында» Россия Федерациясе төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы боерыгының 4.1 пунктына таянып, Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты карар бирә:

1. Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгәннәргә, 2024 елга Түбән Кама шәһәрендә күпфатирлы йортларның торак биналары хуҗалары өчен торак бинасына түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын билгеләргә, торак бинаны карап тоту өчен түләү күләмен 7,2 процент күләмендә билгеләү турында карар кабул итәргә.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
торак сәясәте бүлеге җитәкчесе Р.Ф. Хәйруллин

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044881